Башкортстан Республикасы буенча 2010 елгы Бөтенрусия халык исәбен алу нәтиҗәләре

2010 елның октябрендә Русия Федерациясендә чираттагы Бөтенрусия халык исәбен алу үткәрелде. Аның Башкортстан Республикасы буенча беренче кыскача нәтиҗәләрен Башкортстанстат 2011 елның декабрендә халыкка җиткерде.

Бу материалда җанисәп йомгакларын бастыруны дәвам итәбез. Анда республика халкының аерым социаль-икътисади күрсәткечләре — даими урында яшәү вакыты, белем дәрәҗәсе, милли составы һәм тел белү, икътисади активлыгы турында мәгълүматлар бар. Аларның бер өлеше муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча бирелә.

1. Башкортстан Республикасы халкының төп демографик күрсәткечләре

2010 елның 14 октябренә Бөтенрусия халык исәбен алу мәгълүматлары буенча **Башкортстан Республикасында 4072292** кеше даими яшәгән. Халык саны буенча Башкортстан Идел буе федераль округында — беренче, **Русия Федерациясе субъектлары арасында — җиденче урында.**

Башкортстан Республикасы илебезнең авыл халкы шактый өлешен тәшкил иткән төбәкләре исәбендә. Җанисәп нәтиҗәләре буенча, республика халкының 60,4 проценты шәһәрдә, 39,6 проценты авылда яши. Тоташ алганда Русия урбанизацияләнгән ил булып кала, шәһәр халкы 73,7 процент тәшкил итә.

2010 елгы Бөтенрусия халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча республикада яшәүчеләрнең **уртача яше** — 37,9 (2002 елда — 36,4). Халыкның яшь төркемнәре нисбәте соңгы җанисәп вакытында түбәндәгечә: 0 — 15 яшьлек балалар һәм үсмерләр — 742,3 мең кеше (18,2%), эшкә сәләтле яшьтәгеләр — 25093 мең кеше (61,6%), эшкә сәләтле яшьтән өлкәнрәкләр — 820,2 мең кеше (20,2 процент).

Уртача алганда республикада 1000 ир-атка 1139 хатын –кыз туры килә. Җанисәп нәтиҗәләре республиканың шәһәр торак пунктларында ир-атлар белән хатын-кызлар арасындагы нисбәт проблемасының кискенләшүен күрсәтә (1000 ир-атка 1185 хатын-кыз).

2. Даими урында яшәү вакыты

Туган урыны турындагы сорау барча халыкка бирелде. Җанисәп нәтиҗәләре буенча туган урынын күрсәткән кешеләрдән 3568 мең кеше (89,3%) — республикада, 429,7 мең кеше (10,7 %) Башкортстаннан читтә туган. (Аларның 275 меңе — Русиянең башка субъектларында) 149,6 меңе — элекке совет республикалары территориясендә, 5 меңе дөньяның башка илләрендә туган). 74,5 мең кеше үзенең туган урынын күрсәтмәгән.

Даими урында яшәү вакыты буенча (торак пунктта даими яшәү чоры) халыкның җаваплары түбәндәгечә: яшәү вакытын күрсәткән кешеләрнең 44,5 проценты — туганнан алып яши, 55,5 проценты даими яшәү урынын алмаштырган (Русия буенча шул тәртиптә 46,2 һәм 53,8 процент). 2002 һәм 2010 еллардагы җанисәпләр арасында туганнан алып яшәүчеләр саны 17,4 процентка кимегән.

	Даими яшәү урынын күрсәткән шәхси йорт хуҗалыкларында яшәүчеләр			
	туганнан алып		туганнан алып түгел	
	2002	2010	2002	2010
	Кеше			
Барлык халык	2517121	1757316	1546699	2192133
шәһәрдә	1472906	1146945	1117297	1208077
авылда	1044215	610371	429402	984056
	1000 кешегә			
Барлык халык	619	445	381	555
шәһәрдә	569	487	431	513
авылда	709	383	291	617

Шәһәр халкы арасында туганнан алып даими яшәүчеләр — 48,7 процент, авылда — 38,3 процент. Ир-атлар — 42,5 процент (Русия буенча — 44,5%), хатын-кызлар — 46,3 процент (47,7%).

Халыкның даими урында яшәү вакыты
(яшәү вакытын күрсәткәннәр, кеше)

	Даими урында туганнан алып яшәмиләр	Шулардан күчү елын күрсәткәннәр				
		2006-2010	2001-2005	1996-2000	1992-1995	1991 һәм аннан алда-рак
Барлык халык	**2192133**	**402850**	**250631**	**227414**	**186994**	**1124244**
	100	18,4	11,4	10,4	8,5	51,3
Шәһәр халкы	**1208077**	**204815**	**127814**	**113761**	**96459**	**665228**
	100	16,9	10,6	9,4	8,0	55,1
Авыл халкы	**984056**	**198035**	**122817**	**113653**	**90535**	**459016**
	100	20,1	12,5	11,6	9,2	46,6

Даими яшәү урынын алмаштырган кешеләр арасында 51 процеттан күбрәге соңгы даими яшәү урынында 19 ел һәм аннан да озаграк яшәгән, 10-18 ел яшәүчеләр — 19 процентка якын, 5-9 ел яшәүчеләр — 11,4 процент, 5 ел һәм аннан да азрак яшәүчеләр — 18,4 процент.

3. Халыкның белем дәрәҗәсе

2010 елгы җанисәп җәмгыятьнең белем дәрәҗәсен чагылдыручы мөһим күрсәткечләрне ачыклады.

Югары уку йорты дипломнары булган белгечләр саны Башкортстанда, 2002 ел белән чагыштырганда, 1,5 тапкыр диярлек арткан һәм җанисәп вакытына белем дәрәҗәсен күрсәткән 15 һәм республикада яшәүче аннан да өлкәнрәк һәр 1000 кешегә 175 кеше туры килгән (югары уку йортын тәмамлаганнан соң алган белемне дә кертеп).

Шуны әйтеп үтәргә кирәк, ир-атлар белән чагыштырганда, хатын-кызларның белемлелек позициясе ныгый бара. 2010 елгы җанисәп нәтиҗәләре буенча белем дәрәҗәсен күрсәткән 15 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк хатын-кызлар һәм ир-атлар арасыннан 1000 кешегә 194 хатын-кыз һәм 152 ир-ат югары уку йорты дипломы барлыгын әйткән.

Урта һөнәри белеме булган кешеләр саны белем дәрәҗәсен күрсәткән 15 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк 1000 кешегә 334 тәшкил итә. Биредә ир-атлар һәм хатын-кызлар сан буенча тигез төркемдә (333 һәм 336).

Соңгы елларда **башлангыч һөнәри белем** күрсәткече төшә бара. 2002 елда Башкортстанда яшәүче һәр мең кешегә шундый белем дәрәҗәсе булган 183 кеше туры килсә, 2010 елда бу сан ике тапкыр диярлек — 94 кешегә кадәр кимегән. Башлангыч һөнәри белемле кешеләр арасында ир-атлар хатын-кызларга караганда 1,6 тапкыр күбрәк.

Ир-атларның һәм хатын-кызларның белем дәрәҗәсе
(белем дәрәҗәсен күрсәткән 15 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк 1000 кешегә)

	Барлыгы	Ир-атлар	Хатын-кызлар
Белем дәрәҗәсен күрсәткән 15 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк барлык халык, шул исәптән түбәндәге белемле:	1000	1000	1000
Һөнәри белемле			
югары (югары уку йортын тәмамлаганнан соң алган белемне кертеп)	175	152	194
тулы булмаган югары	40	38	42
урта	334	333	336
башлангыч	94	120	73
гомуми белем			
урта (тулы)	167	183	153
тәп	117	122	113
башлангыч	66	49	81
башлангыч гомуми белеме булмаганнар	6	4	8

4. Башкортстан Республикасы халкының икътисади активлыгы

2010 елгы җанисәптә 15-72 яшьлек кешеләрнең исәп алу башлануга бер атна калуга мәшгульлеге тикшерелде.

Җанисәп нәтиҗәләре буенча республикада 15-72 яшьлек икътисади актив халык 1959,1 мең кеше (икътисади активлыгын күрсәткән шушы яшьтәгеләрнең 65,9 проценты) тәшкил итте. Иң югары икътисади активлык 40-44 яшьлекләргә туры килә.

Икътисади актив халыкның өлеше
(икътисади активлыгын күрсәткән тиешле яшьтәге халык санына карата, процентларда)



Җанисәп кысаларында халык биргән җаваплар буенча республикада гомум эшсезлек дәрәҗәсе, тоташ алганда, икътисади актив халык санына карата 9,8 процент тәшкил итте. Республика районнары һәм шәһәрләре буенча зур гына аерма сизелә: Уфа районында һәм Октябрьский шәһәрендә иң аз күрсәткеч теркәлгән — аларның һәркайсында икътисади актив халык санына карата 7,1 процент. Иң зур күрсәткеч Мишкә районында — 20,4 процент.

Эш урыннары җитешмәү, шулай ук түбән хезмәт хакы республикада яшәүчеләрне үзе яшәгән торак пункттан читтә эш эзләргә мәҗбүр итә. Русия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә Башкортстанда даими яшәүче 81,2 мең кеше эшли (республикада эшләүче халыкның 4,6 проценты).

Русия Федерациясенең башка субъектларында эшләүче Башкортстан Республикасында яшәүчеләр санының бүленеше (Русия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә эшләүче республика халкы саныннан, процентларда)



Республикадан читкә акча эшләү өчен, нигездә, ир-атлар чыга (Русия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә эшләүчеләрнең гомум санының 87,8 проценты). Хезмәт мигрантларының күпчелеге авыл җиреннән (53,6 процент).

Чит илләрдә республикадан 840 кеше эшли, шуларның 217се — БДБ илләрендә, 623се — башка илләрдә. (115е — Италиядә, 77се — АКШта, 58е — Төркиядә, 33е — Германиядә һәм Испаниядә, 19ы — Грециядә).

5. Башкортстан Республикасы халкының милли составы һәм телләр белү

Җанисәп халкының милли составы турындагы бердәнбер мәгълүмат чыганагы булып тора.

Русия Федерациясе Конституциясенә ярашлы, халыктан җаваплар алу барышында кешенең милләте исәп алучы хезмәткәрләр тарафыннан һәркемнең үзенең күрсәтүе буенча язылды. 14 яшькә кадәр балаларның, шулай ук акыл һәм физик үсешендә кимчелекләр булган кешеләрнең милләтен ата-аналар (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр һәм башка законлы вәкилләр) атады.

2010 елгы җанисәп Башкортстанда 160 милләт һәм аларга керүче 13 этник төркем вәкилләре яшәвен күрсәтте. Күпсанлы милләтләрнең 9 булуы ачыкланды, аларга караучылар 10 мең кешедән арта. Өч милләт (урыслар, башкортлар һәм татарлар) вәкилләре республика халкының 90 процентын тәшкил итә (3,6 миллион кешедән күбрәк).

Милләтләр буенча гомум халык саныннан тыш, җанисәптә күпсанлы милләт вәкилләренең социаль-демографик күрсәткечләре (яше, җенесе, никахта торуы һ.б.) турында мәгълүматлар алынды. Иң “яшьләр” булып — марилар (уртача яше — 36,4) һәм башкортлар (36,7), иң “карты” булып украиннар (50,1 яшь) һәм мордвалар (48,3 яшь) тора.

Иң күпсанлы милләтләр вәкилләренең уртача яше

	Ике җенес тә	Ир-атлар	Хатын-кызлар		Ике җенес тә	Ир-атлар	Хатын-кызлар
Башкортстан Республикасы	37,9	35,6	39,9				
урыслар	38,2	35,5	40,5	марилар	36,4	34,6	38,0
башкортлар	36,7	34,6	38,5	украиннар	50,1	47,4	52,3
татарлар	38,2	36,1	40,1	мордвалар	48,3	45,3	50,9
чувашлар	39,9	37,8	41,7	удмуртлар	39,1	36,2	41,6

Башкорт, урыс һәм татар милләтләре вәкилләре арасында яшь төркемнәре нисбәте буенча кайбер аермалар күзәтелә: башкортлар арасында эшкә сәләтле кешеләрдән яшьрәкләр күбрәк (20,1 процент), татарлар арасында — эшкә сәләтләләр (63,0 процент), урыслар арасында эшкә сәләтле яшьтән өлкәнрәкләр (21,9 процент) күбрәк. Республика буенча әлеге яшь категорияләре шул тәртиптә 18,2 процент, 61,6 процент һәм 20,2 процент тәшкил итә.

Ир-атлар һәм хатын-кызлар саны нисбәте буенча украиннарда аерма зуррак — 1000 ир-атка 1212 хатын-кыз туры килә (милләт вәкилләренең 74,2 проценты шәһәрдә яши), мордваларда —1164 (58,8 процент), белорусларда — 1179 (54,9 процент), урысларда — 1180 (76,7 процент). Марилар арасында күрсәткеч берникадәр тигезләшә — 1000 ир-атка — 1097 хатын-кыз (66,3 процент — авыл халкы), чувашларда — 1123 (57,1 процент), башкортларда — 1126 (59,3 процент). Күрүебезчә, хатын-кызларның ир-атлардан күбрәк булуы күбесенчә шәһәрдә яшәүче этносларда күзәтелә.

Күпсанлы милләтләр буенча халыкның никахлашу структурасы түбәндәгечә

	Никахта торуын күрсәткән 16 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк 1000 кешегә					
	1989	2002	2010	1989	2002	2010
	барлык халык			башкортлар		
беркайчан да никахта тормаганнар	193	212	215	212	224	230
никахта торучылар	648	600	589	648	600	583
толлар	107	111	115	98	110	114
аерылышучылар, аерылганнар	50	76	82	39	66	74
	урыслар			татарлар		
беркайчан да никахта тормаганнар	155	209	205	184	213	216
никахта торучылар	663	582	577	662	615	601
толлар	114	117	122	106	98	106
аерылышучылар, аерылганнар	65	91	96	46	74	77

Милләтен һәм телләр белүен күрсәткән республикада яшәүчеләр арасында 3910,5 мең кеше (98 процеттан артык) урыс телен белә, шуларның 1918 меңе өчен ул бердәнбер тел булып тора.

Русия халыклары телләреннән татар (1063,5 мең кеше) һәм башкорт (935,8 мең кеше), мари (81,2 мең кеше) һәм чуваш (75,4 мең кеше) телләрен белү еш күрсәтелә. Чит телләрдән күпчелек инглиз (172 мең кеше) һәм немец (45,3 мең кеше) телләрен белә.

Беренче тапкыр җанисәп барышында чукрак, чукрак-телсез һәм начар ишетүче гражданнарга кул хәрәкәтләре телен белү турындагы сорау бирелде. Республикада яшәүче 4059 кеше шушы телне белүен күрсәткән.

Башкортстан күптеллелек киң таралган төбәкләр исәбендә. Республика халкының яртысы диярлек — ике һәм аннан да күбрәк, шулардан 382,5 мең кеше өч һәм аннан да күбрәк тел белә.

2010 елда җанисәп программасына туган тел турындагы сорау кайтарылды. Җавап бирүчеләрнең 45 проценты туган теле итеп урыс телен күрсәткән. Урыслардан тыш, барлык милләт вәкилләре арасында, уртача алганда, 75,4 процент очракта туган тел итеп үз милләте теле күрсәтелгән.

Күпсанлы милләтләр халыкларының туган тел буенча бүленеше
(туган телен күрсәткән, тиешле милләттән булган 1000 кешегә)

	Туган тел итеп күрсәткәннәр		
	милләте теле	урыс теле	башка милләтләр теле (урыс теленнән тыш)
Урыслар	998	х	2
Башкортлар	753	77	169
Татарлар	853	139	7
Чувашлар	766	225	8
Марилар	884	111	5
Украиннар	231	765	4
Мордвалар	567	431	2
Удмуртлар	896	86	18
Белоруслар	122	875	3

6. Башкортстан Республикасында яшәүчеләрнең торак шартлары

Җанисәп нәтиҗәләре буенча хосусый йорт хуҗалыкларындагы халыкның 97,4 проценты — шәхси (бер фатирлы) аисә күпфатирлы йортларда, 2,5 проценты — тулай торакларда һәм 0,1 проценты башка торак биналарда яши

Башкортстан Республикасында хосусый йорт хуҗалыкларында яшәүчеләрне торак бина төрләре буенча бүлү

	Кеше			Йомгакка карата процентларда		
	барлыгы	шәһәрдә	авылда	барлыгы	шәһәрдә	авылда
Торак бина төрен күрсәткән барлык халык	4027941	2429364	1598577	100	100	100
шул исәптән яшиләр: шәхси (бер фатирлы) һәм күпфатирлы йортларда	3923061	2334997	1588064	97,4	96,1	99,3
шулардан: шәхси (бер фатирлы) йортларда	1485578	304544	1181034	36,9	12,5	73,9
аерым фатирларда	2289675	1909565	380110	56,8	78,6	23,8
коммуналь фатирларда	78405	73384	5021	1,9	3,0	0,3
фатир төрен күрсәтмәгәннәр	69403	47504	21899	1,7	2,0	1,3
тулай торакларда	101881	92883	8998	2,5	3,8	0,6
кунакханәләрдә	637	484	153	0,02	0,02	0,01
башка торак биналарда	2362	1000	1362	0,1	0,04	0,1

1971-1995 елларда төзелгән шәхси (бер фатирлы) аисә күпфатирлы йортларда хосусый йорт хуҗалыкларындагы халыкның — 48,4 проценты, 1957-1970 елларда төзелгән йортларда — 25 проценты, соңгы 15 елда (1996-2010 елларда) төзелгән йортларда 17,6 проценты яши. Халыкның шәһәр һәм авыл җирендә торак биналар төзелү еллары буенча бүленеше түбәндәгечә:



Халыкның күпчелек өлеше — 42,4 проценты — кирпечтән, таштан салынган йортларда, 32,4 проценты — агач йортларда, 22 проценты панельләрдән, блоклардан төзелгән йортларда яши.

2010 елгы җанисәптә торак биналарны төзекләндерү төрләрен өйрәнүче сораулар сизелерлек киңәйтелде.

Шәхси йортларны, аерым һәм коммуналь фатирларны төзекләндерү

	Шәһәр һәм авыл торак пунктлары	Шәһәр торак пунктлары	Авыл торак пунктлары
Төзекләндерүнең түбәндәге төрләреннән файдаланучы йорт хуҗалыклары, (процентларда):			
электр	98,6	98,1	99,5
идәнгә куелган электр плитәсе	5,7	5,7	5,7
челтәр газы	77,2	83,3	67,8
сыекландырылган (баллонлы газ)	7,3	1,2	16,8
үзәктән җылыту	55,2	83,5	11,2
шәхси корылмалардан, казанлыклардан җылыту	30,2	12,7	57,4
мич	13,3	1,9	30,8
коммуналь системадан сууткәргеч	68,3	91,5	32,2
шәхси системадан сууткәргеч	6,0	2,9	10,8
торактан читтә сууткәргеч, колонка	10,0	2,5	21,6
кое, скважина аисә су тәэминатының башка чыганагы	15,0	2,1	35,1
үзәктән кайнар су тәэминаты	43,3	69,5	2,5
шәхси су җылыткычлардан кайнар су тәэминаты	16,5	17,2	15,5
коммуналь канализация системасы аша су түгү	55,6	84,5	10,6
шәхси канализация системасы аша су түгү	5,1	2,9	8,6
торбалар системасы аша чокырга су түгү һ.б	9,7	5,8	15,7
торак эчендә юдырылып төшерелүче бәдрәф	59,6	86,9	17,2
тораста башка тәр бәдрәф (биобәдрәфне дә кертеп)	0,5	0,4	0,6
торактан читтәге бәдрәф	38,0	10,3	81,2
тораста ванна яисә душ	54,4	83,0	9,9
торактан читтә ванна/яисә душ	0,3	0,4	0,1
мунча, сауна	34,5	8,7	74,7
йорттагы чүп үткәргеч	19,3	31,6	0,2
торактан читтә чүп җыйгыч	34,7	48,4	13,4
махсус машина белән чүп чыгару	13,5	13,9	12,8
тораста кухня яисә кухня почмагы	97,2	96,9	97,6
аерым корылмада кухня яисә кухня почмагы	0,5	0,3	0,7
стационар телефон элемтәсе	55,4	65,4	39,8
телевидение антеннасы	90,8	90,2	91,7
чыбыклы радио	12,2	19,5	1,0
Интернет челтәре	33,9	43,9	18,3

Республиканская общественно-политическая газета “Кызыл таң”. Учредители: Государственное собрание — Курултай, Правительство Республики Башкортостан. Издается с 1 марта 1918 года на татарском языке.
Выходит ежедневно, кроме воскресенья и понедельника. Издается ежемесячный журнал “Аллюки”.

Баш мөхәррир
Фаил ФӘТХЕТДИНОВ.
Мөхәрририят: Рим Әхмәтов (җаваплы секретарь), Фәнис Гәрәев, Рәфис Сәяхов, Фәрит Фаткуллин (баш мөхәррир урынбасарлары), Олег Төхвәтуллин, Венера Хәкимова.

Редакциянең адресы: 450079, БР, Уфа, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13, 6нчы кат.
Адрес редакции: 450079, РБ, Уфа, ул. 50-летия Октября,13, 6-й этаж.
kyzyltan@mail.ru

Гәзит Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2008 елның 24 сентябрендә теркәлде.
Теркәлү саны — ПИ №ФС 77-33268
Күләме – 2 басма табак
Гомум тиражы — 15021 данә
Заказ № 211.
Гәзит “Кызыл таң”ның компьютер цехында җыелды һәм “Башкортостан” республика дәүләт нәшрияты типографиясендә басылды: 450079, БР, Уфа-79, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13, 2нче кат, тел. 272-88-73.
Газета отпечатана в типографии государственного республиканского издательства “Башкортостан”. 450079, РБ, Уфа-79, ул. 50-летия Октября, 13, 2-й этаж, тел. 272-88-73.

Телефоннар:
Кабул итү бүлмәсе — 272-13-61
баш мөхәррир урынбасарлары — 272-97-71; 273-50-56
җаваплы секретарь — 272-74-05
Бүлекләр:
сәясәт, икътисад һәм милли проблемалар — 272-58-40
әдәбият һәм сәнгать — 272-35-22
авыл тормышы һәм үз хәбәрчеләр челтәре — 273-46-19
яңалыклар — 272-75-68
хатлар һәм социаль мәсьәләләр — 272-82-07; 272-67-48
рәссам — 272-75-21
реклама — 272-62-27
маркетинг — 272-35-70
бухгалтерия — 273-43-43
төрҗемәчеләр — 272-74-52
“Әллүки” журналы — 272-62-19
Факс — 273-88-01, 272-62-27
Үз хәбәрчеләреңә:
Раевка 8-937-30-97-417
Югары Тәтешле 34778-3-61-73
Югары Яркәй 8-917-384-33-81
Языково 34747-4-01-88

Гәзит чыгышларына карата килгән хатларга җавап бирелми, кулъязмалар, фотолар, рәсемнәр рецензияләнми, кире кайтарылмый. Редакциянең консультация булеге юк. Авторлар фикеренең редакциянеке белән туры килүе зарури түгел.
® Шушындый билге куелган мәкаләләр коммерция нигезендә басыла.
Реклама һәм игъланнарның эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы.

“Кызыл таң”ның индексы:
атнага биш тапкыр басылганыныкы — 50602
атнага өч тапкыр —31087
атнага бер тапкыр — 31084
“Әллүки” журналы — 50709

Безнең дәүләт банкы реквизитлары:
ГУП РБ Редакция газеты“Кызыл таң”
Филиал ОАО “УралСиб” г.Уфы
р/с 40602810700000000020
к/с 30101810600000000770
БИК 048073770
ИНН 0278014101
КПП 027801001
ОКПО 31226910
ОКВЭД — 22.12
Дежур: Р. НИЗАМОВА.

© “Кызыл таң” №13 (24127).

Башкортстан Республикасының муниципаль берәмлекләре буенча 15-72 яшьтәге икътисади актив халык саны

	Барлыгы, кеше	Шул исәптән					Гомум эшсезлек дәрәҗәсе, %	
		Икътисади актив халык	шулардан		икътисади актив булмаган халык	икътисади активлыгын күрсәтмәгәннәр	барлыгы	эшкә сәләтле яшьтәгеләр
			икътисадта эшләүчеләр	эшсезләр				
Башкортстан Республикасы	**3059894**	**1959093**	**1767032**	**192061**	**1015578**	**85223**	**9,8**	**10,0**
Шәһәр округлары:								
Уфа шәһәре	839233	546857	504260	42597	243086	49290	7,8	8,0
Агыйдел шәһәре	13535	8882	7493	1389	3566	1087	15,6	15,8
Күмертау шәһәре	51248	33044	29698	3346	15235	2969	10,1	10,4
Нефтекама шәһәре	104358	70387	65022	5365	32284	1687	7,6	7,7
Октябрьский шәһәре	84199	56496	52462	4034	26403	1300	7,1	7,3
Салават шәһәре	117171	78894	73001	5893	37333	944	7,5	7,4
Сибай шәһәре	48754	28447	25812	2635	17287	3020	9,3	9,5
Стәрлетамак шәһәре	210202	141928	129440	12488	63917	4357	8,8	8,8
Межгорье шәһәре ябык административ территориаль берәмлеге	14007	9418	8387	1031	2785	1804	10,9	11,5
Муниципаль районнар:								
Әбҗәлил	32396	20043	17455	2588	12120	233	12,9	13,1
Әлшәй	32186	19229	16506	2723	12506	451	14,2	14,3
Архангель	13065	7396	6070	1326	5556	113	17,9	18,2
Аскын	15238	9018	7346	1672	6184	36	18,5	18,8
Авыргазы	26717	15665	14091	1574	10818	234	10,0	10,3
Баймак	40895	24671	20723	3948	15938	286	16,0	16,1
Баймак шәһәре	12730	8433	7432	1001	4226	71	11,9	11,9
авыл биләмәләре	28165	16238	13291	2947	11712	215	18,1	18,2
Бакалы	19957	11865	10562	1303	7893	199	11,0	11,1
Балтач	14994	8688	7782	906	6138	168	10,4	10,6
Бәләбәй	77003	51134	46896	4238	25255	614	8,3	8,4
Бәләбәй шәһәре	46326	31468	29385	2083	14467	391	6,6	6,7
Приют поселогы	15364	10132	8933	1199	5080	152	11,8	11,9
авыл биләмәләре	15313	9534	8578	956	5708	71	10,0	10,1
Балакатай	14384	8558	6995	1563	5632	194	18,3	18,6
Белорет	79588	50779	45124	5655	26998	1811	11,1	11,4
Белорет шәһәре	51966	33790	31334	2456	16651	1525	7,3	7,4
авыл биләмәләре	27622	16989	13790	3199	10347	286	18,8	19,2
Бишбүләк	18821	11532	9803	1729	7221	68	15,0	15,3
Бөре	46425	26489	23485	3004	19422	514	11,3	11,7
Бөре шәһәре	33502	18751	16939	1812	14411	340	9,7	10,1
авыл биләмәләре	12923	7738	6546	1192	5011	174	15,4	15,6
Благовар	18868	12104	10761	1343	6458	306	11,1	11,3
Благовещен	37073	24646	22593	2053	11828	599	8,3	8,5
Благовещен шәһәре	25785	17965	16726	1239	7384	436	6,9	7,0
авыл биләмәләре	11288	6681	5867	814	4444	163	12,2	12,3
Бүздәк	22388	13361	11927	1434	8748	279	10,7	10,8
Борай	17806	9602	8396	1206	8021	183	12,6	12,7
Бөрҗән	11106	6873	5625	1248	4151	82	18,2	18,4
Гафури	23598	13864	11282	2582	9558	176	18,6	18,7
Дәүләкән	31189	18918	16946	1972	11490	781	10,4	10,5
Дәүләкән шәһәре	17813	11350	10265	1085	5830	633	9,6	9,6
авыл биләмәләре	13376	7568	6681	887	5660	148	11,7	11,8
Дуван	22894	13933	11977	1956	8764	197	14,0	14,2
Дүртөйле	46722	29904	27173	2731	16207	611	9,1	9,2
Дүртөйле шәһәре	23392	15565	14218	1347	7427	400	8,7	8,7
авыл биләмәләре	23330	14339	12955	1384	8780	211	9,7	9,7
Ярмәкәй	12254	7377	6517	860	4744	133	11,7	11,7
Зианчура	19403	11027	9103	1924	8057	319	17,4	17,7
Зилаер	11915	7398	5965	1433	4447	70	19,4	19,7
Иглин	36721	23407	21435	1972	12933	381	8,4	8,5
Илеш	24807	15841	14204	1637	8862	104	10,3	10,5
Ишембай	67899	43040	38126	4914	23449	1410	11,4	11,7
Ишембай шәһәре	50140	32664	29708	2956	16237	1239	9,0	9,1
авыл биләмәләре	17759	10376	8418	1958	7212	171	18,9	19,3
Калтасы	18660	11531	9793	1738	6982	147	15,1	15,3
Караидел	20484	12576	10772	1804	7747	161	14,3	14,6
Кырмыскалы	37546	24795	22143	2652	12441	310	10,7	10,8
Кыйгы	13576	8384	6963	1421	4847	345	16,9	17,1
Краснокама	20221	12783	11238	1545	7368	70	12,1	12,2
Күгәрчен	22118	13136	10807	2329	8872	110	17,7	18,1
Куергазы	18277	10954	9707	1247	7172	151	11,4	11,5
Кушнаренко	20126	11243	9786	1457	8638	245	13,0	13,1
Мәләвез	65515	42699	38577	4122	21995	821	9,7	9,8
Мәләвез шәһәре	45636	30780	28068	2712	14278	578	8,8	8,9
авыл биләмәләре	19879	11919	10509	1410	7717	243	11,8	12,0
Мәчетле	17818	10859	9586	1273	6723	236	11,7	11,9
Мишкә	18121	9894	7874	2020	8047	180	20,4	20,5
Миякә	20325	12613	11210	1403	7587	125	11,1	11,3
Нуриман	14863	8975	7789	1186	5783	105	13,2	13,5
Салават	18964	11832	9810	2022	6924	208	17,1	17,2
Стәрлебаш	14452	9050	7966	1084	5350